| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**ГЛАВА БИКУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**<br>**БИККОЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**<br>**БАШЛЫГЫ** |

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Биккол авылы **КАРАР**

30 октябрь 2019 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегендә
халык җыенын кертү мәсьәләсе буенча оештыру турында
һәм гражданнарның үзара салым акчаларын куллану турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы "Биккол авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 14 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Биккол авылы, Мәктәп урамы, 15 нче а йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегендәге Биккол авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2019 елның 16 ноябрендә 19 сәгать 00 минутка Биккол авылы, Мәктәп урамы, 15 нче а йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегендәге Биккол авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2019 елның 19 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Биккол авылы, Мәктәп урамы, 15 нче а йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегендәге Биккол авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аеруга сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарыла.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

6. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«2020 елда Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлегендәге Биккол авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

- Су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләргә китерү буенча эшләр башкару.

- Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге торак пункты чикләрендәге юлларны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Биккол авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Әхмәтшина